СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Решение

№ 1-50 | 13 март 2020 ел

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы
карар **кабул итте**:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне хупларга (№1 кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе» «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 5 июнендә кабул ителгән 1-31 номерлы карары белән расланган ачык тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. «»Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2020 елның 14 нче апрелендә Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитетының административ бинасының утырышлар залында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Мамадыш районы, Урта Кирмән авылы, Ленин ур., 16А .

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Хасанов Б.Ф. – 2 нче номерлы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2) Нагимов Ф.Г. – 4 нче номерлы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Насибуллин И.Ю.– 7 нче номерлы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

6. Эшче төркемгә Урта Кирмән авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм гражданнарның «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, аны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы каравына 2020 елның 17 нче апреленә кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны 2020 елның 16 нчы мартына кадәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге Советы рәисе Б.Ф.Хасанов

СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге
Советының 13 март 2020 ел,
1-50 карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:
«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар кабул итү, рөхсәтсез корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү».

2. 31 статьяның 10 пунктында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.;

3.50 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелеш объектларының иң чик параметрларына туры китерү турындагы карарны Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә кабул итә.».

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл жирлеге Советының
13 март 2020 ел ; 1-50
карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашуы турында тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына тәкъдимнәр язма рәвештә, Ф. и. А. и., туган елы, төзәтмәләр таблицасы рәвешендә яшәү урыны күрсәтеп, Урта Кирмән авыл жирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422171,Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Урта Кирмән авылы, Ленин урамы, 16А йорт, тел./факс (885563) 2-92-38, e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru :

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И. А. и., адрес,) Эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр әлеге карар игълан ителгән көннән алып эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422171, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Урта Кирмән авылы, Ленин урамы, 16А йорт, шәхсән яки почта аша («Устав турында фикер алышу» яки «ачык тыңлаулар»тамгасы белән конвертта), шулай ук телефон/факс (885563) 2-92-38, e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru,

Гаризалар ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл жирлеге»муниципаль берәмлеге Советына һәм башлыгына тапшырыла.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл жирлеге Советы рәисе /Б.Ф.Хасанов/